| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.11.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3278** |
|---|---|---|

2023 елга «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары буенча норматив чыгымнарны раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат- мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны кушымтада каралганча расларга.
2. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ әлеге карарның 1 пункты белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan. ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 нче елның 28 ноябрендәге
3278 номерлы карарына карата
кушымта

**2023 елга**
**Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат- мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җире | 104308 |
| | авыл җире | 105678 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җире | 154787 |
| | авыл җире | 159325 |